ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**25.04.2019**

Зеленодольск
шәһәре.

**КАРАР**
**№ 974**

Массакүләм спорт һәм гавами чаралар уздыру вакытына гомуми файдаланудагы юлларны вакытлыча ябу турында

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә Бөек Ватан сугышында җиңүнең еллыгын бәйрәм иткәндә юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү максатында, Зеленодольскмуниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Массакүләм чаралар уздыру чорында җәяүлеләр зонасын оештыру белән транспорт чаралары хәрәкәтен 2019 елның 9 маенда 9.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр Зеленодольск шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының түбәндәге участокларында вакытлыча туктатырга:

- Заикин урамы чатыннан алып Беренче Май урамы чатына кадәр Ленин урамын;
- Карл Маркс урамы чатыннан алып Ленин урамы чатына кадәр Татарстан урамын.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск районы буенча ЭЭМ бүлегенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- әлеге карарның 1 пункты нигезендә Зеленодольск шәһәрендә чаралар үткәрүне тәэмин итү өчен барлык төр транспорт чаралары хәрәкәтен туктатуны оештырырга;
- чаралар барышында катнашучыларның һәм тамашачыларның куркынычсызлыгын тәэмин итү, аларны үткәрү чорында транспорт хәрәкәтен җайга салу буенча кирәкле чаралар күрергә;
- чаралар үткәрү урыннарына якын урамнарда килеп урнашкан оператив хәлне исәпкә алып, транспорт хәрәкәтен чикләү, яки ябу буенча карарлар кабул итәргә.

3. «Зеленодольск муниципаль районының төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ Зеленодольск шәһәренең Карл Маркс урамында пассажирлар транспорты хәрәкәтен оештырырга.

4. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы Д.С. Анисимовка әлеге карарны

Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo) tatarstan.ru ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk. tatarstan.ru) урнаштырырга һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сапожников